КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 17 март г.Казань № 232

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 03 апрель, 263 нче карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен түләүне гражданнарның аерым категорияләренә компенсацияләүгә Татарстан Республикасы чыгымнарын финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен түләүне гражданнарның аерым категорияләренә компенсацияләүгә Татарстан Респуб-ликасы чыгымнарын финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 03 апрель, 263 нче карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен түләүне гражданнарның аерым категорияләренә компенсацияләүгә Татарстан Республикасы чыгымнарын финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «шәхси счет» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счеты» сүзләренә алмаштырырга;

4 – 7 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, иң чик финанслау күләмнәре Министрлыкка аның заявкалары буенча җиткерелгәннән соң, иң чик

финанслау күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җиткерә.

5. Министрлык «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба - Үзәк) гражданнарның кредит оешмаларында үзләре ачкан шәхси счетларына күчерү өчен финанслауның иң чик күләмен җиткерә.

6. Үзәк Министрлыкка тапшыра:

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 числосына кадәр, финанслашу максатларында субсидияләр бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап;

субсидиядән файдалану нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап:

ай саен - хисап чорыннан соңгы айның өченче эш көненнән дә соңга калмыйча;

ел саен - хисап чорыннан соңгы айның өченче эш көненнән дә соңга калмыйча;

еллык аныкланган хисап - хисап елыннан соң килүче елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча.

7. Министрлык Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интегральләшкән мәгълүмат системасыннан файдаланып Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән субсидия бирү турындагы килешү нигезендә рәвешләр һәм сроклар буенча хисаплар тапшыра.»;

8 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин